# У.Шекспир әсәрләренең татар теленә тәрҗемәләрендә реалияләрнең бирелеше

*Г.Ә. Нәбиуллина, Э.Н. Денмөхәммәтова, Г.Н.Шангареева*

Хезмәт № **18 –7 (Г) /2009 (Г)** номерлы *грант кысаларында язылды*

“Әгәр музалар[1] инглиз телен белсәләр, алар Шекспирның нәфис гыйбарәләрен кулланып сөйләрләр иде” [Shakespeare 1965]. Әлеге юллар Шекспир чорында яшәгән әдәбият белгечләренең аның иҗатына югары бәя биргәннәре турында шикләнергә урын калдырмый. Уильям Шекспирның бүгенге көнгә 37 драма әсәре, 2 поэмасы һәм 154 сонеттан торган шигырьләр циклы килеп җиткән. XIX гасырның 20 нче елларыннан башлап Шекспирның әсәрләре рус, француз, алман телләренә тәрҗемә ителүе билгеле, татар теленә тәрҗемәләре исә XX гасырның 40 нчы елларында гына күренә башлый. Шекспринның татар теленә төрле елларда тәрҗемә ителгән трагедия һәм комедия әсәрләре җыелмасы 2006 – 2007 нче елларда 2 томны үз эченә алган сайланма әсәрләр җыентыгында дөнья күрде. (Шекспир У. Сайланма әсәрләр: 2томда / Уильям Шекспир, 2т.: Трагедияләр, комедияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 518 б., Шекспир У. Сайланма әсәрләр: 2томда / Уильям Шекспир, 1т.: Трагедияләр, комедия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 614 б.). Татар тәрҗемәчеләрен бигрәк тә “Король Лир” трагедиясе җәлеп иткән, икенче урында – “Ромео һәм Джульетта” трагедиясе. Шулай ук “Гамлет”, “Отелло”, “Тискәрегә - авызлык” драмаларының татар теленә дә тәрҗемә ителүе билгеле. Шекспир әсәрләрен татар укучысына җиткерүдә Н.Исәнбәт, Г.Шамуков, И.Әхмәтҗанов, Ш.Мөдәррис һ.б. шәхесләр күп көч куя.

Шекспир әсәрләренең тәрҗемәләрен фәнни-теоретик яктан өйрәнү мәсьәләсенә килгәндә, рус, француз, алман телләренә тәрҗемә ителгән кайбер әсәрләрен тикшереп язылган фәнни хезмәтләр булуы мәгълүм [Эткинд 1963; Аникст 1974; Комарова 1989]. Татарчага булган тәрҗемәләрне өйрәнеп язылган Р.А.Әюпованың кандидатлык хезмәте [Аюпова 2001] һәм Х.Курбатовның аерым күзәтүләре [Курбатов 1957] бар. Х.Курбатов үзенең “Шекспир сонетлары татар

---

[1] Муза – борынгы грекларда фән һәм сәнгать алиһәсе.

телендә” дип исемләнгән мәкаләсендә Ш.Мөдәррис башкарган сонетлар тәрҗемәсенә уңай бәя биреп, “образлар системасы гына түгел, шигырьнең ритмик агышы, рифмалашу тәртибе дә нәкъ оригиналдагыча диярлек”, – дип яза. Р.А.Әюпованың кандидатлык диссертациясендә исә Шекспир әсәрләрендәге драматург үзе инглиз теленә әйләнешкә керткән фразеологизмнарны татар теленә нинди алымнар белән тәрҗемә ителү мәсьәләсе яктыртыла.

Мәшһүр драматургның әсәрләрендә күп кулланылган лексик сурәтләү чараларының берсе – реалияләр. Билгеле бер халыкка яки илгә генә хас иҗтимагый тормыш һәм материаль көнкүреш реалияләрен белдерә торган сүзләрне бер телдән икенче телгә дөрес итеп күчерүнең төп шарты – ул реалияләрнең үзләрен яхшы белү.

Тәрҗемә белгечләре реалияләрне төркемләүнең төрле юлларын тәкъдим итәләр. И.С.Алексеева классификациясендә реалияләр өч төргә бүленә:

1. Географик реалияләр: а) физик география терминнары: прерия, саванна; б) эндемика (билгеле бер урынга гына хас хайван, кош-корт, үсемлек төрләре) терминнары: баобаб, кенгуру.

2. Этнографик реалияләр: а) кием-салым: кимоно; б) корылмалар һәм көнкүреш җиһазлары: сауна; в) милли эшчәнлек төрләре: икебана, скоморох; г) йолалар, ырымнар, уеннар: вендетта, тамада; д) мифология һәм культлар: тролль, синагога; е) үлчәү һәм акча берәмлекләре: аршин.

3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр: кантон, большевиклар [Алексеева 2004: 181].

Р.А.Юсупов реалия ләрне тәрҗемә итүнең өч юлын күрсәтә:

1. Тулы яки өлешчә транслитерация (реалия исемен турыдан-туры алу яки аның тамырын тәрҗемә теле аффикслары белән бергә куллану).

2. Реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау.

3. Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдалану

Р.А.Юсупов фикеренчә, “бер телдән икенче телгә һичьюгында тасвирлау юлы (аңлатмалы юл) белән тәрҗемә ителмәслек сүз юк. Ләкин, оригинал телендәге лексик кыскалыкны саклау һәм бирелгән әйбер яки төшенчәнең специфик характерын күрсәтү өчен, транслитерация алымы кулайрак” [Юсупов 2008: 75].

1. У.Шекспир әсәрләрендә географик, этнографик, иҗтимагый-сәяси характердагы күп санлы реалияләр урын ала. Аларның күпчелеге транслитерация ысулы ярдәмендә тәрҗемә ителгәннәр.

| | |
|---|---|
| mandragora | мандрагора (Г.Шамуков) |
| satyr | сатир (Н.Исәнбәт) |
| gentleman | җентельмен (Н.Исәнбәт) |
| Duke | Дож (Г.Шамуков) |
| Senator | Сенатор (Г.Шамуков) |
| Lord | Лорд (Н.Исәнбәт, И.Әхмәтҗанов) |

Транслитерацияләнгән сүз сирәк кулланылганда, бигрәк тә тәрҗемә теленә беренче тапкыр кучерелгәндә, ул сүзгә аңлатма һәм тиешле контекст кирәк була. Мисаллардан күренгәнчә, *лорд, сенатор* кебек сүзләрнең һәркайсына да аңлатма биреп торуның кирәге юк дип саныйбыз, чөнки күпчелек очракта реалия исеменең мәгънәсе контексттан аңлашылып тора.

Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдаланып тәрҗемә ителгән географик реалияләр:

| | |
|---|---|
| coloquintida | әрем (Г.Шамуков) |

Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдаланып тәрҗемә ителгән этнографик реалияләр:

| | |
|---|---|
| frize | постау (Г.Шамуков) |
| galleys | флот (Г.Шамуков) |
| pint (0,568 л. сыешлы савыт) | уймак (Г.Шамуков) |
| gondolier | көймәче (Г.Шамуков) |

Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдаланып тәрҗемә ителгән иҗтимагый-сәяси реалияләр:

| | |
|---|---|
| knight | рыцарь (Н.Исәнбәт, И.Әхмәтҗанов) |
| madam | синьора (Г.Шамуков) |
| Duke | шамакай (И.Әхмәтҗанов) |
| Earl | Герцог (Н.Исәнбәт, И.Әхмәтҗанов) |
| gentleman | Граф (Н.Исәнбәт, И.Әхмәтҗанов) |
| | дворян (Г.Шамуков) |

Күзәтүләрдән күренгәнчә, функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган туган тел чараларыннан файдалану У.Шекспир әсәрләрен тәрҗемә иткәндә шактый еш кулланылган. Дөрес, *герцог, граф, синьора* кебек сүзләр шулай ук Көнбатыш телләреннән алынган, әмма бу очракта әлеге лексик берәмлекләр башкаларының тәрҗемәсе буларак кулланылган. Шулай да, *gondolier* Венециядә генә таралыш алган һөнәр исеме, *гондольер* дип тәрҗемә ителә, *гондола* (борын һәм койрык өлешләре күтәртелеп, бизәкләп ясалган озын көймә) белән идарә итүче дип аңлатыла. Тәрҗемәдә мондый специфик реалияләрнең төшеп калуы вакыйгалар географиясен ачыграк күз алдына китерергә мөмкинлек бирми дигән караштa торабыз.

2. Реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау.

| | |
|---|---|
| clog – тяжелая гиря, которую приковывали к ноге преступника, чтобы препятствовать его побегу (М.Морозов) | богау салу (Г.Шамуков) |
| crusade – португальская монета (М.Морозов) | алтын (Г.Шамуков) |

Тәрҗемә практикасында сирәк очрый торган әлеге ысул Шекспир тәрҗемәләрендә дә аз кулланыла.

У.Шекспирның әсәрләрендә татарчага тәрҗемә ителми калган реалияләр дә теркәлде (җәяләр эчендә М.Морозов аңлатмалары): *stoop* (сосуд для вина в виде большого кувшина с узким горлышком); *pottle* (мера жидкости, 2,27 л.); *jot*

(английская мера длины). Әлеге реалияләрнең аңлатмалары да татар текстларында бөтенләй кулланылмаган.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә мөмкин: У.Шекспир драмаларын тәрҗемә иткәндә, мәгънә саклануга күбрәк әһәмият бирү, поэтик форманы оригиналга якын итеп төзергә омтылу максатыннан тәрҗемәчеләр транслитерация алымына мөрәҗәгать итәләр. Тулы яки өлешчә транслитерация ысулы ярдәмендә күбрәк географик реалияләр тәрҗемә ителгән, ә функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдалану алымы күбрәк иҗтимагый-сәяси реалияләрне тәрҗемә иткәндә кулланылган. Татар тәрҗемәчеләре этнографик реалияләр тәрҗемәсендә әлеге ике юлга да бердәй дәрәҗәдә диярлек мөрәҗәгать иткәннәр.

**Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар**


1. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений / И.С.Алексеева. – СПб.: СПбГУ; М.: Издательский центр “Академия”, 2004. – с 181.
2. Аникст А.А. Шекспир. Ремесло драматурга / А.А.Аникст. – М.: Сов. писатель, 1974. – 607 с.
3. Аюпова Р.А. Фразеологизмы-шекспиризмы и способы их перевода на татарский язык. Дисс... канд. филол. наук. – Казань, 2001. – 229с.
4. Ионина А.А. Английская грамматика: Теория и практика. – 4-е изд., испр. / А.А.Ионина, А.С.Саакян. – М.: Айрис-пресс, 2003. – 448 с.
5. Комарова В.П. Метафоры и аллегории в произведениях Шекспира / В.П.Комарова. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1989. – 199 с.
6. Курбатов Х. Шекспир сонетлары татар телендә / Х.Курбатов // Совет әдәбияты. – 1957. – №6. – 117-118 б.
7. Shakespeare W. Sonnets / W. Shakespeare. – M.: Progress Publishers, 1965. – p.185.
8. Shakespeare W. Hamlet, Prince of Denmark / W.Shakespeare. – M.: Издательство литературы на иностранных языках, 1939. – 192 с.
9. Shakespeare W. Othello, The Moor of Venice. Полный текст трагедии со словарем и комментариями проф. М.Морозова. Под общ. редакцией проф. С.С.Динамова / W.Shakespeare. – M.: Издательское товарищество иностранных рабочих СССР, 1936. – 186 с.
10. Shakespeare W. The Tragedy of King Lear / W.Shakespeare. – M.: Academia, 1936. – 392 p.
11. Шекспир В. Трагедия о Короле Лире / Пер. с англ. М.Кузмина / Под ред. С.Динамова и А.Смирнова / Коммент. А.Смирнова. – М. – Л.: Academia, 1936. – 392 с.
12. Шекспир У. Сайланма әсәрләр: 2томда / Уильям Шекспир, 1т.: Трагедияләр, комедия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 614 б.
13. Шекспир У. Сайланма әсәрләр: 2томда / Уильям Шекспир, 2т.: Трагедияләр, комедияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 518 б.
14. Шекспир В. Трагедии / Пер. с англ. Б.Пастернака. – Л.: Худож. лит., 1982. – 384 с.
15. Эткинд Е. Поэзия и перевод / Е.Эткинд. – М. – Л.: Сов. писатель, 1963. – 80-88 с.

16. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы / Р.А.Юсупов. – Казан. – Татар. кит. нәшр., 2008, 74 б.